МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.04.2024 Казан шәһәре № 21

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең перспективалы икътисадый тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карары нигезендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләрне һәм компенсацияләрне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә торган башка максатларга субсидияләр бирү өлешендә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78¹ статьясының 1 пунктындагы икенче һәм дүртенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләүгә вәкаләтле булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карары нигезендә **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең перспективалы икътисадый тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карары нигезендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләрне һәм компенсацияләрне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә торган башка максатларга субсидияләр бирү өлешендә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү секторына әлеге боерыкны теркәлгән көненнән алып бер эш көне эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге боерык 2024 елның 9 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары О.В.Пелевинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
29.01.2024 ел, № 21 боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең перспективалы икътисадый тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карары нигезендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләрне һәм компенсацияләрне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә торган башка максатларга субсидияләр бирү өлешендә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең перспективалы икътисадый тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Учреждение) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карары нигезендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләрне һәм компенсацияләрне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә торган башка максатларга субсидияләр бирү өлешендә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – башка максатларга субсидия) бирү максатын, аларның күләмен һәм бирү шартларын һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылыкны билгели.

1.2. Башка максатларга субсидияләр Учреждениегә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору буенча чараларны финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр тәэмин итү өлешендә түләүләр, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына һәм (яки) дәүләт бюджеттан тыш фондларга салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен

исәпкә алып, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда Учреждение хезмәткәрләренә түләнә.

1.3. Татарстан Республикасы бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучы буларак башка максатларга субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә китерелгән Учреждениегә карата гамәлгә куючы (алга таба – Гамәлгә куючы) функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тора.

1.4. Башка максатларга субсидияләр Учреждение чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә бирелә:

- Учреждение хезмәткәрләренең хезмәт хакы;
- эштән азат ителгән хезмәткәрләргә компенсацияләр;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр.

## 2. Башка максатларга субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирү Гамәлгә куючы тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга, билгеләнгән тәртиптә Гамәлгә куючыга башка максатларга субсидияләр бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә башкарыла.

2.2. Башка максатларга субсидияләр алу өчен Учреждение Гамәлгә куечыга түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада расланган форма буенча башка максатларга субсидияләр алуга гариза;

Учреждениенең башка максатларга субсидияләр алу өчен гариза бирелгән вакытта гамәлдә булган штат расписаниесе;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын бирү зарурлыгын, шул исәптән башка максатларга субсидияләр суммасын исәпләү-нигезләүне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында түләүләр алучы Учреждение хезмәткәрләре саны турында мәгълүматны үз эченә алган аңлатма язуы;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче затның (җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләрен үтәве турында белешмә формасын һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча гариза бирелгән айның 17 нче көненә бирелгән, салым түләүче затның (җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләрен үтәве турында салым органы белешмәсе;

гариза бирү аеның 17 нче көненә Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиешле, түләү вакыты узган бурычларының, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә башка максатларга бирелгән субсидияләрнең,

бюджет инвестицияләренең булмавы турында Учреждение җитәкчесе һәм баш хисапчы, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган белешмә, Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, аварияле (гадәттән тыш) хәлне булдырмый калу, аварияле (гадәттән тыш) хәл барлыкка килгән очракта аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару, законлы көченә кергән суд актлары, башкару документлары буенча бурычларны каплау очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш.

Тапшырылган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Учреждение мөһере белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Документларның күчермәләре Учреждениенең мөһере белән беркетелергә һәм моңа вәкаләт бирелгән затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесенең үз кулы белән таныкланган булырга тиеш. Учреждение җитәкчесенең язма мөрәҗәгате Учреждение мөһере белән беркетелергә һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланырга яки Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән расланган булырга тиеш.

2.3. Башка максатларга субсидия алу өчен документлар Гамәлгә куючы тарафыннан алынган көнне журналда теркәлә, ул номерланырга, тегелгән һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән документлар алынганнан соң өч эш көне эчендә аларны карый, аларда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм башка максатларга субсидия бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирүдән баш тарту нигезләре:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

әлеге Тәртипнең 2.2 пунктына ярашлы рәвештә Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

Документлар тулы булмаган комплектта тапшырылган һәм (яки) әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, шулай ук Учреждение тәкъдим иткән документлардагы мәгълүмат дөрес булмаган очракта, Гамәлгә куючы әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә аларны Учреждениегә кире кайтара, документларны кире кайтару сәбәпләре турында язмача хәбәр итә. Учреждение документларны кире кайтару сәбәпләрен бетергәннән соң документларны кабат җибәрергә хокуклы.

2.4. Гариза бирү аеның 17 нче көнендә Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняларны, штрафларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавы;

Татарстан Республикасы бюджетына, шул исәптән башка норматив хокукый актлар нигезендә бирелгән, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләнелмәгән бурычларның һәм Татарстан Республикасы бюджетына дәүләт

ярдәменең башка төрләре буенча түләү вакыты узган башка бурычның булмавы (Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, аварияле (гадәттән тыш) хәлне булдырмый калу, аварияле (гадәттән) тыш хәл килеп чыккан очракта, аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару буенча чараларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү, законлы көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча бурычларны каплау очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында каралган башка очраклардан тыш).

2.5. Башка максатларга субсидияләр күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә билгеләнә.

Башка максатларга субсидияләр бирү буенча бюджет ассигнованиеләре күләмен билгеләүче норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелгән очракта, башка максатларга бирелә торган субсидияләр күләме үзгәртелергә мөмкин.

2.6. Башка максатларга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә Гамәлгә куючы һәм Учреждение арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешүнең бер төр формасын раслау турында» 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешүнең бер төр формасына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 20 декабрендәге 17-131 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча субсидияләр бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзелә, анда түбәндәге нигезләмәләр була:

башка максатларга субсидияләр бирү максатлары;

башка максатларга субсидияләр күләме;

башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренең кыйммәтләре;

башка максатларга субсидияләрне күчерү сроклары (графигы);

хисаплылык тапшыру чорлары;

өстәмә хисаплылык (кирәк булганда);

Учреждение Килешүдә билгеләнгән максатларны һәм шартларны һәм тәртипне үтәмәгән очракта, башка максатларга субсидияләр суммаларын кайтару тәртибе һәм вакыты;

Килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Гамәлгә куючыга башка максатларга субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта;

башка максатларга субсидияләр күләмен үзгәртү нигезләре һәм шартлары;

берьяклы рәвештә, шул исәптән Учреждениенең башка максатларга субсидияләр бирү максатларын һәм шартларын бозуы сәбәпле, Гамәлгә куючы карары буенча Килешүне вакытыннан алда туктату өчен нигезләр;

Учреждение тарафыннан Килешүне берьяклы тәртиптә өзүнең тыелган булуына бәйле рәвештә;

Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән башка нигезләмәләр (кирәк булганда).

2.7. Гамәлгә куючы Учреждениегә башка максатларга субсидияне Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирүгә финанслауның җиткерелгән чик күләмнәре күләмендә башка максатларга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күчерә.

2.8. Учреждениегә башка максатларга бирелгән субсидияләр белән операцияләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Учреждениенең аерым шәхси счетларында исәпкә алына.

2.9. Башка максатларга субсидия аның чыганагы булган Учреждение чыгымнарын санкцияләү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.10. Агымдагы финанс елы дәвамында башка максатларга субсидияләр акчалары хисабына башкарыла торган чыгымнарны өстәмә финанслау кирәк булган очракта, Учреждение Гамәлгә куючыга башка максатларга субсидияләр күләмен арттыру турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итә ала, өстәмә финанс ресурслары кирәклегенә исәп-хисап-нигезләү бирә.

2.11. Учреждение башка максатларга бирелә торган субсидияләр күләмен арттыру турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать иткән очракта, Гамәлгә куючы кергән мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә Учреждениенең әлеге тәкъдимен һәм өстәмә финанс акчаларын бүлеп бирү кирәклегенә расламаны карый, Гамәлгә куючыга башка максатларга субсидияләр өчен бюджет акчаларын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә өстәмә килешүләр төзү юлы белән Килешүгә үзгәрешләр кертү инициативасы белән чыга.

2.12. Башка максатларга субсидия бирү нәтиҗәсе булып Учреждение хезмәткәрләренә башка максатларга бирелгән субсидиянең 100 процентлы күләмендә башка максатларга субсидия бирү аеннан соңгы айның 15 көненнән дә соңга калмыйча түләүләр суммасы тора.

## 3. Хисаплылыкка карата таләпләр

3.1. Учреждение Гамәлгә куючыга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бер төр формасына теркәлгән формалар буенча раслаучы документлар белән түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып башка максатларга субсидияләр булган чыгымнар турында хисап, башка максатларга субсидияләр бирү аеннан соң 15 көннән дә соңга калмыйча;

башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап, – башка максатларга субсидияләр бирү аеннан соң 15 көннән дә соңга калмыйча.

Учреждение Гамәлгә куючыга әлеге Тәртипкә теркәлгән форма буенча (2 нче кушымта) түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын үтәү турында хисап, – башка максатларга субсидияләр бирү аеннан соң 15 көннән дә соңга калмыйча.

3.2. Бюджет акчаларының керүен һәм тотылуын бюджет (бухгалтерлык) исәпкә алу Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алып барыла.

## 4. Башка максатларга субсидияләрне бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольлекне һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру тәртибе

4.1. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы Учреждениегә башка максатларга субсидияләр бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен зарури контрольдә тота.

4.2. Учреждение башка максатларга субсидияләр алу өчен төгәл булмаган белешмәләрне һәм документларны тапшырган өчен яки субсидияләрне башка максатларга кулланган өчен, әлеге Тәртип нигезендә башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен, шулай ук башка максатларга субсидияләрне тоту максатларын бозган өчен, әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән хисап-лылыкны тапшырмаган, башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән өчен җаваплы була.

4.3. Башка максатларга субсидия бирү елында файдаланылмаган башка максатларга субсидиянең калган өлеше башка максатларга субсидия бирү елыннан да соңга калмыйча  Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш, Гамәлгә куючы тарафыннан бу акчаларга ихтыяҗ булуы турында карар кабул ителгән очраклардан тыш.

Субсидия бирү елында кулланылмаган акчаларны әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга юнәлдерү ихтыяҗы булган очракта, Учреждение Гамәлгә куючыга башка максатларга субсидия бирелгән айның 15 көненнән дә соңга калмыйча, мондый ихтыяҗны дәлилләүче мәгълүмат тапшыра.

Гамәлгә куючы Учреждениедән әлеге пунктның  икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат алынган көннән соң 10 календарь көненнән соңга калмыйча, бюджет законнары нигезендә, Учреждениедә башка максатларга субсидия бирү елында кулланылмаган башка максатларга субсидияләрнең калган өлешен бүтән максатларга юнәлдерүдә ихтыяҗы булуы яки булмавы турында карар кабул итә.

Гамәлгә куючы башка максатларга субсидия бирү елында кулланылмаган башка максатларга субсидиянең калган өлешен башка максатларга юнәлдерүдә Учреждениенең ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, мондый карар кабул ителгән көннән алып календарь көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Гамәлгә куючы белән Учреждение арасында Килешүгә өстәмә килешү төзелә.

Әлеге Тәртипнең шушы пунктында күрсәтелгән башка максатларга субсидиянең калган өлешен  кире кайтару срокларын бозган очракта, Гамәлгә куючы субсидиянең калган өлешен башка максатларга кайтару вакыты чыккан көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

4.4. Башка максатларга субсидияләр бирүнең максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланган очракта, дәүләт финанс контроле органы һәм (яки) Гамәлгә куючы әлеге факт ачыкланган көннән алып 10 эш көне эчендә Учреждение адресына башка максатларга субсидияләр акчаларын кире кайтару турында язма таләп җибәрә.

Гамәлгә куючы һәм (яисә) дәүләт финанс контроле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә билгеләнеп, башка максатларга субсидияләр

бирү һәм файдалану буенча бозулар ачыкланган очракта, башка максатларга субсидияләр күрсәтелгән факт ачыкланган көннән алып 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

Билгеләнгән вакыт эчендә акча кермәгән очракта, Гамәлгә куючы Россия Федерациясе законнары нигезендә аларны суд тәртибендә түләттерү чараларын күрә.

4.5. Килешүдә күрсәтелгән башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, башка максатларга субсидияләр Гамәлгә куючы һәм (яки) дәүләт финанс контроле органы тарафыннан Учреждениегә тиешле таләп җиткерелгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

4.6. Башка максатларга субсидия бирелгән елда финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып башка максатларга субсидия торган, Учреждение тарафыннан элегрәк түләнгән түләүләрне кире кайтарудан акча күчкән очракта, Гамәлгә куючы Учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кайтарудан алынган акчалар торган үтәмәгән йөкләмәләр (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуы турында башка максатларга субсидия бирелгән елдан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба – Учреждениенең элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгате), шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләре булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен Учреждение тарафыннан аларны файдалану турында карар кабул итә.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып башка максатларга субсидия акчалары торган, Учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан күчкән акчаларны башка максатларга субсидия бирү елында файдалану турындагы карарны Учреждение элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көне эчендә кабул итә.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең перспективалы икътисадый тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карары нигезендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләрне һәм компенсацияләрне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә торган башка максатларга субсидияләр бирү өлешендә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

**20_____ елның «____» _________ башка максатларга субсидияләр алу өчен**
**20 ____ елның «____» _________ № ____ гариза**

______________________________________________________________________

(Учреждение исеме, ИНН/КПП)

______________________________________________________________________

(башка максатларга субсидияләр төре)

| т/с | Максатлы статья исеме | Бюджет чыгымнары классификациясе коды | Башка максатларга субсидияләрне максатчан юнәлеше | Агымдагы финанс елына башка максатларга сорала торган субсидия-ләр суммасы, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| Гариза буенча БАРЛЫГЫ | | | | |

Әлеге гаризага түбәндәге документлар беркетелә:
______________________________________________________________________

Учреждение җитәкчесе ______________________________ /                              /

Учреждениенең баш бухгалтеры _______________________ /                                        /
Мөһер урыны

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең перспективалы икътисадый тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1432 номерлы карары нигезендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләрне һәм компенсацияләрне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләрен үзгәртеп кору чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә торган башка максатларга субсидияләр бирү өлешендә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләренә (контроль нокталарга) ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап (1)
20____ елның «__» _______ буенча

| | | КОДЛАР |
|---|---|---|
| Алучының исеме ______________________________________ | җыелма реестр буенча<br>Салым түләүченең тәңгәллек номеры | |
| Дәүләт хакимияте башкарма органы – Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүченең исеме _________________________________ | җыелма реестр буенча | |
| Документ төре ____________________________________<br>(беренчел – «0», тәгаенләштерелгән – «1», «2», «3», «...»)<br>Ешлыгы: ай саен; квартал; еллык | | |
| Үлчәү берәмлеге: сум. | ОКЕИ буенча | 383 |

| Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсе, контроль нокталар | | | Үлчәү берәмлеге | | Билгесе | | | Ирешү вакыты | | Статус (5) | Тайпылу сәбәбе (6) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| атамасы | код | тибы | атамасы | ОКЕИ буенча коды | план | фактик (2) | фаразый (3) | планлы | фактик (фаразый) (4) | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсе (7) | | | | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль пунктлары (8) | х | | | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| план чорының контроль нокталары (9) | х | | | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

Җитәкче (вәкаләтле зат)
Алучы _______________________________________________ ___________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Башкаручы _______________________________________________ ___________________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (имза)

«__» ________ 20__ ел.

(1) Хисап күрсәткечләре башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләре, контроль пунктлар, аларның планлы кыйммәтләренә ирешү вакыты хисап датасына җиткән, шул исәптән башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләре, үткән хисап чорларында ирешү өчен планлаштырылган контроль пунктлар, шулай ук башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәләре, контроль пунктлар, сроклар нигезендә формалаштырыла хисап чорыннан соң өч ай эчендә планлаштырылган казанышлар. Әгәр килешү федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә саклана торган дәүләт яки башка серне тәшкил итүче мәгълүматны үз эченә алса, тиешле билге ("хезмәт файдалануы өчен" / "яшерен" / "тулысынча яшерен" / "аеруча мөһим") һәм экземпляр номеры куела.

(2) Башка максатларга бирелгән субсидияләрнең фактта ирешелгән нәтиҗә күрсәткече һәм 1 нче графада билгеләнгән контроль нокталар күрсәтелә.

(3) Башка максатларга бирелгән субсидияләрнең фактта ирешелгән нәтиҗә күрсәткечендә һәм 1 нче графада билгеләнгән контроль нокталарда алар буенча ирешү срогы тиешле хисап датасына килеп җитмәгән, 6 нчы графада күрсәтелгән план күрсәткеченнән тайпылу күрсәтелә.

(4) Башка максатларга субсидияләр нәтиҗәсенә, 1 нче графада күрсәтелгән контроль ноктага ирешү вакыты күрсәтелә. Әгәр 6 нчы графада билгеләнгән башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсе хисап чорында ирешелмәгән булса (өлешчә ирешелгән булса), билгеләнгән кыйммәткә ирешүнең фаразланган вакыты күрсәтелә.

(5) Статус күрсәтелә: "О" - тайпылышлар юк, "1" – тайпылышлар бар.

(6) Әгәр билгеләнгән датага башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсенең планлы кыйммәте чынлыкта ирешелмәгән булса, планлы кыйммәттән тайпылу сәбәбе күрсәтелә.

(7) Башка максатларга субсидияләр бирү нәтиҗәсенең исеме күрсәтелә.

(8) Хисап чорында аңа ирешү датасы килеп җиткән контроль пунктның исеме күрсәтелә.

(9) Хисап чорыннан соң өч ай эчендә ирешү планлаштырылган контроль пунктның исеме күрсәтелә.